КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 2 август г.Казань № 559

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 25 май, 424 нче; 2020 ел, 26 август, 744 нче; 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче; 2021 ел, 4 май, 306 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче; 2022 ел, 5 март, 196 нчы; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 6 сентябрь, 964 нче; 2022 ел, 16 ноябрь, 1218 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1483 нче; 2023 ел, 14 апрель, 462 нче; 2023 ел, 5 август, 946 нчы; 2023 ел, 6 октябрь, 1252 нче; 2023 ел, 28 декабрь, 1712 нче; 2024 ел, 10 май, 316 нчы; 2024 ел, 6 август, 623 нче; 2024 ел, 4 сентябрь, 724 нче; 2025 ел, 12 апрель, 222 нче; 2025 ел, 22 май, 347 нче; 2025 ел, 2 июнь, 392 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 1.3 пункттагы «Үзәк махсуслаштырылган аналитик контроль

инспекциясе» сүзләрен «Экология күзәтчелеген тәэмин итү буенча үзәк бүлек» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 22 сентябрь, 895 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1370 нче; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1194 нче; 2023 ел, 4 октябрь, 1226 нчы; 2024 ел, 7 май, 311 нче; 2024 ел, 16 сентябрь, 793 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт инспекторы,» сүзләреннән соң «Экология күзәтчелеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы,» сүзләрен өстәргә;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Югары риск категориясенә кертелгән контроль объектлары өчен план буенча документар тикшерүләр уздыру вакыты ике елга бер планлы документар тикшерү яисә елга бер мәҗбүри профилактик визит ясау тәшкил итә.

Югары риск категориясенә кертелгән контроль объектлары өчен планлы күчмә тикшерүләр уздыру вакыты ике елга бер планлы күчмә тикшерү яисә елга бер мәҗбүри профилактик визит ясау тәшкил итә.

Рискның башка категорияләренә кертелгән контроль обектларына карата планлы контроль (күзәтчелек) чаралары уздырылмый.

Шактый, урта һәм уртача риск категориясенә кертелгән контроль объектлары өчен мәҗбүри профилактик визитлар ясау вакыты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;

3.1 пунктта:

бишенче абзацта «Шул ук вакытта профилактик чаралар» сүзләрен «Әгәр Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, профилактик чаралар» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацка «яисә Федераль законда каралган очракларда Федераль законның 90 статьясында каралган чараларны күрә» сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Министрлык ел саен, төп күрсәткечләргә ирешү турында мәгълүматларны һәм контроль төрләренең индикатив күрсәткечләре турында мәгълүматларны күрсәтеп, төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турында, шул исәптән төп күрсәткечләргә ирешү өчен профилактик чараларның һәм контроль (күзәтчелек) чараларының йогынтысы турында доклад әзерләүне, шулай ук хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча тәкъдимнәр әзерләүне гамәлгә ашыра. Хокук куллану практикасы турында доклад узган ел йомгаклары буенча әзерләнә, Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры боерыгы белән раслана һәм хисап чорыннан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектлардан файдаланып хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлый торган юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга Министрлык тарафыннан контрольдә тотылучы зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видеоконференция элемтәсе яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән профилактик визит уздыру тәкъдим ителә.

Профилактик визит барышында юридик затка, индивидуаль эшкуарга аның эшчәнлегенә йә аның карамагындагы контроль объектларына карата куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның риск критерийларына туры килүе турында, риск категориясен киметү буенча тәкъдим ителә торган ысуллар турында, шулай ук тиешле риск категориясенә кертелүенә карап, контроль объектына карата үткәрелә торган контроль (күзәтү) чаралары төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында мәгълүмат бирелә, ә инспектор контроль объекты белән таныша, контроль объектларын риск категорияләренә кертү өчен кирәкле мәгълүмат җыя һәм контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлү дәрәҗәсен бәяли.

Контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча профилактик визит Федераль законның 52.2 статьясы нигезендә уздырыла.

Мәҗбүри профилактик визит Федераль законның 52.1 статьясы нигезендә һәм тәртибендә үткәрелә.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән, Федераль законның 57 статьясында билгеләнгән нигезләр буенча уздырыла торган контроль (күзәтчелек) чараларын оештыру һәм үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда планнан тыш контроль (күзәтчелек) чараларының төрләре Федераль законның 57 статьясында билгеләнгән контроль (күзәтчелек) чаралары уздыру нигезләренә бәйле рәвештә билгеләнә.»;

4.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Инспекция визиты – билгеле бер юридик зат яисә индивидуаль эшкуар һәм (яисә) хуҗа (җитештерү объектыннан файдаланучы) белән үзара хезмәттәшлек ярдәмендә үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) чарасы. Юридик затның, индивидуаль эшкуарның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) яки контроль объектының урнашу (эшчәнлек гамәлгә ашыру) урыны буенча үткәрелә. Инспекция визиты дистанцион үзара хезмәттәшлек чараларыннан, шул исәптән видеоконференция элемтәсе аша, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин. Инспекция визиты барышында түбәндәге контроль (күзәтчелек) чаралары башкарылырга мөмкин:»;

4.6 пунктта:

икенче абзацта «контроль (күзәтчелек) чаралары» сүзләрен «контроль (күзәтчелек) гамәлләре» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «бер эш көне» сүзләрен «10 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

4.7 пунктта:

дүртенче абзацта «аңлатмалар» сүзен «язма аңлатмалар» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документар тикшерү үткәрү срогы 10 эш көненнән арта алмый. Әлеге срокны исәпләү юридик затка, индивидуаль эшкуарга документаль тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны тапшыру турында таләп җибәрелгән вакыттан алып алар Министрлыкка тапшырылган вакытка кадәр, шулай ук юридик затка, индивидуаль эшкуарга контрольдә тотылучы зат тарафыннан тапшырылган документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклы фикерләр ачыклану турында яисә әлеге документлардагы белешмәләрнең Министрлыкта булган документлардагы һәм (яисә) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында мәгълүмат һәм кирәкле язма аңлатмалар бирү таләбе җибәрелгән вакыттан алып әлеге язма аңлатмалар Министрлыкка бирелгән вакытка кадәр туктатып торыла.»;

4.8 пунктта:

беренче абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Күчмә тикшерү дистанцион үзара хезмәттәшлек чараларыннан, шул исәптән видеоконференция элемтәсе аша, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Планнан тыш күчмә тикшерү бары прокуратура органнары белән килештерелеп (Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары, 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм $12^1$ өлешләре нигезендә аны уздыру очракларыннан тыш) үткәрелергә мөмкин.»;

4.9 пунктта:

беренче абзацта «(куркынычсызлык мониторингын)» сүзләрен «(куркынычсызлык мониторингы)» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «яки әйләнә-тирә мохитне саклауга зыян (зарар) китерү куркынычы турында» сүзләрен «яки әйләнә-тирә мохиткә турыдан-туры зыян (зарар) китерү куркынычы» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.10. Күчмә тикшерү – контрольдә тотылучы затлар тарафыннан әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) чарасы. Күчмә тикшерү оешманың (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу урыны, контроль объектының урнашу урыны буенча үткәрелә. Күчмә тикшерү барышында инспектор һәркем файдалана алган (чикләнмәгән затлар төркеме йөрүгә ачык булган) җитештерү объектларын тикшерүне, пробалар (үрнәкләр) сайлап алуны гамәлгә ашырырга мөмкин. Күчмә тикшерү контрольдә тотылучы затка хәбәр итмичә уздырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.11 пункт өстәргә:

«4.11. Үзара хезмәттәшлек итмичә, контроль (күзәтчелек) чаралары Министрлыкның дәүләт инспекторлары тарафыннан Татарстан Республикасының баш дәүләт

инспекторы, аның урынбасарлары биремнәре (Министрлык эше планнарындагы биремнәрне кертеп) нигезендә үткәрелә.

Күчмә тикшерү барышында һәркем файдалана алган җитештерү объектларында түбәндәге контроль (күзәтчелек) гамәлләре башкарылырга мөмкин: тикшерү, пробалар (үрнәкләр) алу, инструментлар белән тикшерү.

Контроль (күзәтчелек) гамәлләренең нәтиҗәләре контроль (күзәтчелек) чарасы актында теркәлә. Контроль (күзәтчелек) чарасы актының формасы Министрлык боерыгы белән раслана.

Әгәр күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыкланса, Министрлык тарафыннан Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карар кабул ителә.

Контрольдә тотылучы зат тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләр бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карарның үтәлү срогы чыкканнан соң яисә әлеге срок чыкканга кадәр контрольдә тотылучы зат тарафыннан документлар һәм әлеге карар белән тапшырылуы билгеләнгән белешмәләр бирелгәндә яисә мәҗбүри таләпләр үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) кысаларында мәгълүмат алынган очракта, Министрлык тапшырылган документлар һәм белешмәләр, алынган мәгълүмат нигезендә карарның үтәлешен бәяли.

Әгәр әлеге документлар һәм белешмәләр контрольдә тотылучы зат тарафыннан тапшырылмаса яки алар нигезендә яисә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) кысаларында алынган мәгълүмат нигезендә карарның үтәлеше турында нәтиҗә ясау мөмкин булмаса, Министрлык әлеге карарның үтәлешен Федераль законның 66 статьясында билгеләнгән тәртиптә прокуратура органнары белән килештергәннән соң үткәрелергә тиешле күчмә тикшерү, инспекция визиты, рейд тикшерүе яисә документар тикшерү үткәрү юлы белән бәяли. Әгәр әлеге абзацта каралган контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү йомгаклары буенча Министрлык тарафыннан карарның үтәлмәве яисә тиешенчә үтәлмәве ачыкланган булса, ул контрольдә тотылучы затка, аның яңа үтәү срокларын күрсәтеп, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозулар очракларын бетерү турында күрсәтмә бирә. Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә билгеләнгән сроклар эчендә үтәлмәгәндә, Министрлык аның үтәлешен тәэмин итү өчен, әгәр мондый чара законнарда каралган булса, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турындагы таләп белән хәтта судка мөрәҗәгать итеп, чаралар күрә.

Министрлык карарының тулысынча үтәлүе турында мәгълүмат контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына тулы күләмдә кертелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.12 пункт өстәргә:

«4.12. Контроль (күзәтү) чараларын үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне бозу дәлилләрен теркәү өчен фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру, башка дәлилләр теркәү ысуллары кулланылырга мөмкин.

Дәлилләр теркәү ысуллары мәҗбүри таләпләрне бозуны чагылдыра торган теркәү объектын ачык итеп идентификацияләргә мөмкинлек бирергә тиеш.

Контроль (күзәтчелек) чараларын гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу дәлилләрен теркәү өчен фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру, башка дәлилләр

теркәү ысулларын куллану кирәклеге турында карар контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан мөстәкыйль рәвештә кабул ителә.

Мәҗбүри таләпләрне бозу дәлилләрен теркәү өчен карамакта булган теләсә нинди техник чаралар: фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру кулланылырга мөмкин. Фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру һәм әлеге максатлар өчен файдаланылган техник чаралар турында мәгълүмат контроль (күзәтчелек) чарасы актында чагылдырыла.

Аудиога һәм видеога яздыру, контрольдә тотылучы зат белән хезмәттәшлек итеп, контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрү барышында язманың башында һәм ахырында яздыру датасы, урыны, яздыра башлау һәм яздыруны туктату вакыты турында хәбәр итеп гамәлгә ашырыла. Яздыру барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу җентекләп теркәлә, аның урыны һәм характеры күрсәтелә.

Мәҗбүри таләпләрне бозулар буенча дәлилләрне теркәү өчен фотога төшерүдән, аудиога һәм видеога яздырудан файдалану дәүләт серен саклау турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру нәтиҗәләре контроль (күзәтчелек) чарасы актына теркәлә.»;

V бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Министрлык карарларына, аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирү

Хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре (аларның фикеренчә) төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру кысаларында турыдан-туры бозылган юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар судка кадәр түбәндәгеләргә карата шикаять бирергә хокуклы:

контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар үткәрү турындагы карарларга;

контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар актларына, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләргә;

контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар кысаларында Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына);

контроль объектларын тиешле риск категориясенә кертү турындагы карарларга;

контрольдә тотылучы затларның гаризалары буенча мәҗбүри профилактик визитлар үткәрүдән баш тарту турындагы карарларга;

Министрлык тарафыннан профилактик һәм (яки) контроль (күзәтчелек) чаралары йомгаклары буенча контрольдә тотылучы затларга яки контроль объектларына карата кабул ителә торган башка карарларга.

Министрлык яки аның территориаль органнары тарафыннан чыгарылган карарга, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять юридик зат (индивидуаль эшкуар) үз хокукларының бозылуы турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып 30 календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Министрлык яки аның территориаль органнары тарафыннан бирелгән, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәгә карата

шикаять юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан күрсәтмә алынган көннән алып 10 эш көне эчендә бирелергә мөмкин.

Нигезле сәбәп буенча шикаять бирү срогы чыккан очракта, әлеге срок шикаять бирүче затның үтенечнамәсе буенча вәкаләтле орган тарафыннан торгызылырга мөмкин. Шикаять биргән кеше шикаять буенча карар кабул ителгәнгә кадәр аны кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шул ук нигезләр буенча кабат шикаять җибәрү рөхсәт ителми.

Министрлыкның территориаль идарәсе карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгы (башлыгы урынбасары) яисә Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы тарафыннан карап тикшерелә.

Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгы (башлыгы урынбасары) гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы тарафыннан карап тикшерелә.

Татарстан Республикасының экология һәм табигать ресурслары министры карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Татарстан Республикасының экология һәм табигать ресурслары министры тарафыннан карап тикшерелә.

Министрлыкның карарларына, үзәк аппарат кабул иткән карарларга, Министрлыкның үзәк аппаратындагы вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелгән очракта, төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда шикаять Татарстан Республикасының экология һәм табигать ресурслары министры тарафыннан карала.

Шикаять контрольдә тотылучы зат тарафыннан Федераль законның 40 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнә торган шикаять карарга вәкаләтле органга, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан һәм (яисә) дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталларыннан файдаланып, электрон рәвештә (Федераль законның 40 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очрактан тыш) бирелә. Граждан тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул гади электрон имза яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш. Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Шикаять Министрлык тарафыннан Федераль законның 43 статьясында билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелә.

Шикаять Министрлык тарафыннан судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасында теркәлгән көненнән алып иң күбе 15 эш көне эчендә каралырга тиеш. Контроль объектларын тиешле риск категориясенә кертү турындагы карарга карата шикаять иң күбе биш эш көне эчендә карап тикшерелә.

Федераль законның 42 статьясындагы 1 өлешенең 3 – 8 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Министрлык карарларына, аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка шикаять бирү өчен нигез була алмый.»;

VII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VII. Төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары исемлеге

7.1. Юридик затлардан һәм индивидуаль эшкуарлардан норматив хокукый актлар нигезендә алар тарафыннан мәҗбүри тапшырылырга тиеш булган, атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгару, су объектына пычраткыч матдәләр агызу күләмнәренә үзгәреш кертү, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны дәүләт исәбенә кую турындагы гаризада, әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау турындагы декларациядә, узган ел өчен җитештерү экология контролен гамәлгә ашыру турындагы хисапта булган мәгълүматлар белән чагыштырганда барлыкка килгән һәм урнаштырылган калдыклар массасына 10 проценттан артыграк үзгәреш кертү хакында белешмәләр бирелгән хисаплылык һәм башка мәгълүмат бирү барышында мәгълүмат алу.

7.2. Атмосфера һавасын контрольдә тоту автомат станциясеннән, шулай ук Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесеннән әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган ике һәм аннан да күбрәк предприятие йогынтысы зонасында «Эколог-Город» программа комплексы ярдәмендә ясалган нурланыш исәп-хисаплары нигезендә билгеләнә торган атмосфера һавасында пычраткыч матдәләрнең уртача айлык концентрацияләре 20 проценттан күбрәк арту турында мәгълүматлар алу.

7.3. Бер ел эчендә ике һәм аннан күбрәк тапкыр аккредитацияләнгән лабораторияләрдән Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан бирелгән су объектын файдалануга бирү турындагы карарлар буенча суларда пычраткыч матдәләр концентрацияләре пычраткыч матдәләрнең иң чик рөхсәт ителә торган концентрацияләре нормативларыннан 95 проценттан 100 процентка кадәр булу фактлары турында мәгълүмат алу.

7.4. Бер ай эчендә ике һәм аннан күбрәк тапкыр аккредитацияләнгән лабораторияләрдән, Министрлыкның Экология күзәтчелеген тәэмин итү буенча үзәк бүлегеннән, шулай ук «Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесеннән су объектларында агып төшә торган суларны агызу урыннарында пычраткыч матдәләрнең булуы балык хуҗалыгы әһәмиятендәге су объектлары өчен билгеләнгән нормативлардан 95 проценттан 100 процентка кадәр концентрацияләрдә арту фактлары турында мәгълүматны үз эченә алган су объектлары торышын тикшерүләр нәтиҗәләре алу.

7.5. Бер ай эчендә ике һәм аннан күбрәк тапкыр аккредитацияләнгән лабораторияләрдән, Министрлыкның Экология күзәтчелеген тәэмин итү буенча үзәк бүлегеннән атмосфера һавасында пычраткыч матдәләр концентрацияләрен эпизодик үлчәүләр үткәргәндә бер яки берничә чыгару чыганагы булган предприятиенең санитар-саклау зонасы чигендәге җилдән ышык ягыннан атмосфера һавасында пычраткыч матдәләрнең компонент составын 0,5 иң чик рөхсәт ителә торган максималь бер концентрация концентрациясеннән үзгәрү турында белешмәләр алу.

7.6. Юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан элегрәк Министрлыкка дөрес булмаган мәгълүмат тапшырылуын күрсәтә торган гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләрендә (гаризаларында) булган мәгълүмат, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат алу:

хисаплылык һәм норматив хокукый актлар нигезендә тапшырылуы мәҗбүри булган башка мәгълүмат бирү барышында;

дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен документлар тапшырганда.

7.7. Министрлыкка Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы федераль хезмәтенең территориаль органыннан яисә ведомство буйсынуындагы оешмасыннан шәһәр һәм башка җирлек территориясендә тискәре метеорология шартлары турында мәгълүмат керү (атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгару чыганаклары булган һәм тискәре метеорологик шартлар фаразларын алганда атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларны киметү чараларын мәҗбүри үткәрергә тиеш булган юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар өчен) һәм атмосфера һавасын контрольдә тоту автомат станциясеннән һәм күчмә экология лабораторияләреннән атмосфера һавасында пычраткыч матдәләр концентрацияләрен эпизодик үлчәүләр үткәргәндә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган ике һәм аннан күбрәк предприятие йогынтысы зонасында «Эколог-Город» программа комплексы ярдәмендә ясалган нурланыш исәп-хисаплары нигезендә билгеләнә торган атмосфера һавасында пычраткыч матдәләрнең уртача айлык концентрацияләре 20 проценттан күбрәк арту турында мәгълүмат алу.

7.8. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектлар буенча Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән тапшырылуы каралган хисаплылыкта пычраткыч матдәләр чыгарулар, агызулар, барлыкка килә, урнаштырыла торган калдыклар күләме һәм (яки) массасы турында мәгълүматларның узган хисап чоры белән чагыштырганда 30 һәм аннан күбрәк процентка тайпылуы.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 940 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1368 нче; 2022 ел, 25 октябрь, 1137 нче; 2023 ел, 4 октябрь, 1226 нчы; 2024 ел, 7 май, 311 нче; 2024 ел, 2 сентябрь, 714 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт инспекторы,» сүзләреннән соң «Экология күзәтчелеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы,» сүзләрен өстәргә;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Югары риск категориясенә кертелгән контроль объектлары өчен план буенча документар тикшерүләр уздыру вакыты ике елга бер планлы документар тикшерү яисә елга бер мәҗбүри профилактик визит ясау тәшкил итә.

Югары риск категориясенә кертелгән контроль объектлары өчен планлы күчмә тикшерүләр уздыру вакыты ике елга бер планлы күчмә тикшерү яисә елга бер мәҗбүри профилактик визит ясау тәшкил итә.

Рискның башка категорияләренә кертелгән контроль обектларына карата планлы контроль (күзәтчелек) чаралары уздырылмый.

Шактый, урта һәм уртача риск категориясенә кертелгән контроль объектлары өчен мәҗбүри профилактик визитлар ясау вакыты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.»;

3.1 пунктта:

бишенче абзацта «Шул ук вакытта профилактик чаралар» сүзләрен «Әгәр Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, профилактик чаралар» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацка «яисә Федераль законда каралган очракларда Федераль законның 90 статьясында каралган чараларны күрә» сүзләрен өстәргә;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Министрлык ел саен, төп күрсәткечләргә ирешү турында мәгълүматларны һәм контроль төрләренең индикатив күрсәткечләре турында мәгълүматларны күрсәтеп, төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турында, шул исәптән төп күрсәткечләргә ирешү өчен профилактик чараларның һәм контроль (күзәтчелек) чараларының йогынтысы турында доклад әзерләүне, шулай ук хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча тәкъдимнәр әзерләүне гамәлгә ашыра. Хокук куллану практикасы турында доклад узган ел йомгаклары буенча әзерләнә, Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры боерыгы белән раслана һәм хисап чорыннан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларына тискәре йогынты ясый торган эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлый торган юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга Министрлык тарафыннан контрольдә тотылучы затның эшчәнлеге башкарыла торган урын буенча яисә видеоконференция элемтәсеннән яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән профилактик әңгәмә формасында профилактик визит уздыру тәкъдим ителә.

Профилактик визит барышында юридик затка, индивидуаль эшкуарга аның эшчәнлегенә йә аның карамагындагы контроль объектларына карата куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның риск критерийларына туры килүе турында, риск категориясен киметү буенча тәкъдим ителә торган ысуллар турында, шулай ук тиешле риск категориясенә кертелүенә карап, контроль объектына карата үткәрелә торган контроль (күзәтү) чаралары төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында мәгълүмат бирелә, ә инспектор контроль объекты белән таныша, контроль объектларын риск категорияләренә кертү өчен кирәкле мәгълүмат җыя һәм контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлү дәрәҗәсен бәяли.

Контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча профилактик визит Федераль законның 52.2 статьясы нигезендә уздырыла.

Мәҗбүри профилактик визит Федераль законның 52.1 статьясы нигезендә һәм тәртибендә үткәрелә.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән, Федераль законның 57 статьясында билгеләнгән нигезләр буенча уздырыла торган контроль (күзәтчелек) чараларын оештыру һәм үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда планнан тыш контроль (күзәтчелек) чараларының төрләре Федераль законның 57 статьясында билгеләнгән контроль (күзәтчелек) чаралары уздыру нигезләренә бәйле рәвештә билгеләнә.»;

4.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Инспекция визиты – билгеле бер юридик зат яисә индивидуаль эшкуар һәм (яисә) хуҗа (җитештерү объектыннан файдаланучы) белән үзара хезмәттәшлек ярдәмендә үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) чарасы. Юридик затның, индивидуаль эшкуарның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) яки контроль объектының урнашу (эшчәнлек гамәлгә ашыру) урыны буенча үткәрелә. Инспекция визиты дистанцион үзара хезмәттәшлек чараларыннан, шул исәптән видеоконференция элемтәсе аша, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин. Инспекция визиты барышында түбәндәге контроль (күзәтчелек) чаралары башкарылырга мөмкин:»;

4.6 пунктта:

икенче абзацта «контроль (күзәтчелек) чаралары» сүзләрен «контроль (күзәтчелек) гамәлләре» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «бер эш көне» сүзләрен «10 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

4.7 пунктта:

дүртенче абзацта «аңлатмалар» сүзен «язма аңлатмалар» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документар тикшерү үткәрү срогы 10 эш көненнән арта алмый. Әлеге срокны исәпләү юридик затка, индивидуаль эшкуарга документаль тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны тапшыру турында таләп җибәрелгән вакыттан алып алар Министрлыкка тапшырылган вакытка кадәр, шулай ук юридик затка, индивидуаль эшкуарга контрольдә тотылучы зат тарафыннан тапшырылган документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклы фикерләр ачыклану турында яисә әлеге документлардагы белешмәләрнең Министрлыкта булган документлардагы һәм (яисә) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында мәгълүмат һәм кирәкле язма аңлатмалар бирү таләбе җибәрелгән вакыттан алып әлеге язма аңлатмалар Министрлыкка бирелгән вакытка кадәр туктатып торыла.»;

4.8 пунктта:

беренче абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Күчмә тикшерү дистанцион үзара хезмәттәшлек чараларыннан, шул исәптән видеоконференция элемтәсе аша, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Планнан тыш күчмә тикшерү бары прокуратура органнары белән килештерелеп (Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары, 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм $12^1$ өлешләре нигезендә аны уздыру очракларыннан тыш) үткәрелергә мөмкин.»;

4.9 пунктта:

беренче абзацта «(куркынычсызлык мониторингын)» сүзләрен «(куркынычсызлык мониторингы)» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «яки Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыклары кишәрлекләренә зыян (зарар) китерү куркынычы турында» сүзләрен «яки Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыклары кишәрлекләренә турыдан-туры зыян (зарар) китерү куркынычы» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.10. Күчмә тикшерү – контрольдә тотылучы затлар тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) чарасы. Күчмә тикшерү оешманың (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу урыны, контроль объектының урнашу урыны буенча үткәрелә. Күчмә тикшерү барышында инспектор һәркем файдалана алган (чикләнмәгән затлар төркеме йөрүгә ачык булган) җитештерү объектларын тикшерүне, пробалар (үрнәкләр) сайлап алуны гамәлгә ашырырга мөмкин. Күчмә тикшерү контрольдә тотылучы затка хәбәр итмичә уздырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.11 пункт өстәргә:

«4.11. Үзара хезмәттәшлек итмичә, контроль (күзәтчелек) чаралары Министрлыкның дәүләт инспекторлары Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы, аның урынбасарлары биремнәре (Министрлыкның эш планнарындагы биремнәрне кертеп) нигезендә үткәрелә.

Күчмә тикшерү барышында һәркем файдалана алган җитештерү объектларында түбәндәге контроль (күзәтчелек) гамәлләре башкарылырга мөмкин: тикшерү, пробалар (үрнәкләр) алу, инструментлар белән тикшерү.

Контроль (күзәтчелек) гамәлләренең нәтиҗәләре контроль (күзәтчелек) чарасы актында теркәлә. Контроль (күзәтчелек) чарасы актының формасы Министрлык боерыгы белән раслана.

Әгәр күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыкланса, Министрлык тарафыннан Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карар кабул ителә.

Контрольдә тотылучы зат тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләр бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карарның үтәлү срогы чыкканнан соң яисә әлеге срок чыкканга кадәр контрольдә тотылучы зат тарафыннан документлар

һәм әлеге карар белән тапшырылуы билгеләнгән белешмәләр бирелгәндә яисә мәҗбүри таләпләр үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) кысаларында мәгълүмат алынган очракта, Министрлык тапшырылган документлар һәм белешмәләр, алынган мәгълүмат нигезендә карарның үтәлешен бәяли.

Әгәр әлеге документлар һәм белешмәләр контрольдә тотылучы зат тарафыннан тапшырылмаса яки алар нигезендә яисә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) кысаларында алынган мәгълүмат нигезендә карарның үтәлеше турында нәтиҗә ясау мөмкин булмаса, Министрлык әлеге карарның үтәлешен Федераль законның 66 статьясында билгеләнгән тәртиптә прокуратура органнары белән килештергәннән соң үткәрелергә тиешле күчмә тикшерү, инспекция визиты, рейд тикшерүе яисә документар тикшерү үткәрү юлы белән бәяли. Әгәр әлеге абзацта каралган контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү йомгаклары буенча Министрлык тарафыннан карарның үтәлмәве яисә тиешенчә үтәлмәве ачыкланган булса, ул контрольдә тотылучы затка, аның яңа үтәү срокларын күрсәтеп, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозулар очракларын бетерү турында күрсәтмә бирә. Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә билгеләнгән сроклар эчендә үтәлмәгәндә, Министрлык аның үтәлешен тәэмин итү өчен, әгәр мондый чара законнарда каралган булса, күрсәтмәне мәҗбүри үтәү турындагы таләп белән хәтта судка мөрәҗәгать итеп, чаралар күрә.

Министрлык карарының тулысынча үтәлүе турында мәгълүмат контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына тулы күләмдә кертелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.12 пункт өстәргә:

«4.12. Контроль (күзәтү) чараларын үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне бозу дәлилләрен теркәү өчен фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру, башка дәлилләр теркәү ысуллары кулланылырга мөмкин.

Дәлилләр теркәү ысуллары мәҗбүри таләпләрне бозуны чагылдыра торган теркәү объектын ачык итеп идентификацияләргә мөмкинлек бирергә тиеш.

Контроль (күзәтчелек) чараларын гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу дәлилләрен теркәү өчен фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру, башка дәлилләр теркәү ысулларын куллану кирәклеге турында карар контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан мөстәкыйль рәвештә кабул ителә.

Мәҗбүри таләпләрне бозу дәлилләрен теркәү өчен карамакта булган теләсә нинди техник чаралар: фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру кулланылырга мөмкин. Фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру һәм әлеге максатлар өчен файдаланылган техник чаралар турында мәгълүмат контроль (күзәтчелек) чарасы актында чагылдырыла.

Аудиога һәм видеога яздыру, контрольдә тотылучы зат белән хезмәттәшлек итеп, контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрү барышында язманың башында һәм ахырында яздыру датасы, урыны, яздыра башлау һәм яздыруны туктату вакыты турында хәбәр итеп гамәлгә ашырыла. Яздыру барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу җентекләп теркәлә, аның урыны һәм характеры күрсәтелә.

Мәҗбүри таләпләрне бозуга дәлилләрне теркәү өчен фотога төшерүдән, аудиога һәм видеога яздырудан файдалану дәүләт серен саклау турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Фотога төшерү, аудиога һәм видеога яздыру нәтиҗәләре контроль (күзәтчелек) чарасы актына теркәлә.»;

V бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Министрлык карарларына, аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирү

Төбәк дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру кысаларында хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре, аларның фикеренчә, турыдан-туры бозылган юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар түбәндәгеләргә карата судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар үткәрү турындагы карарларга;

контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар актларына, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләргә;

контроль (күзәтчелек) чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар кысаларында Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына);

контроль объектларын тиешле риск категориясенә кертү турындагы карарларга;

контрольдә тотылучы затларның гаризалары буенча мәҗбүри профилактик визитлар үткәрүдән баш тарту турындагы карарларга;

Министрлык тарафыннан профилактик һәм (яки) контроль (күзәтчелек) чаралары йомгаклары буенча контрольдә тотылучы затларга яки контроль объектларына карата кабул ителә торган башка карарларга.

Министрлык яки аның территориаль органнары тарафыннан чыгарылган карарга, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять юридик зат (индивидуаль эшкуар) үз хокукларының бозылуы турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып 30 календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында Министрлык яки аның территориаль органнары тарафыннан бирелгән күрсәтмәгә карата шикаять юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан күрсәтмә алынган көннән алып 10 эш көне эчендә бирелергә мөмкин.

Нигезле сәбәп буенча шикаять бирү срогы чыккан очракта, әлеге срок шикаять бирүче затның үтенечнамәсе буенча вәкаләтле орган тарафыннан торгызылырга мөмкин. Шикаять биргән кеше шикаять буенча карар кабул ителгәнгә кадәр аны кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шул ук нигезләр буенча кабат шикаять җибәрү рөхсәт ителми.

Министрлыкның территориаль идарәсе карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгы (башлыгы урынбасары) яисә Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы тарафыннан карап тикшерелә.

Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгы (башлыгы урынбасары) гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы тарафыннан карап тикшерелә.

Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Татарстан Республикасының экология һәм табигать ресурслары министры тарафыннан карап тикшерелә.

Министрлыкның карарларына, үзәк аппарат кабул иткән карарларга, Министрлыкның үзәк аппаратындагы вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелгән очракта, төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда шикаять Татарстан Республикасының экология һәм табигать ресурслары министры тарафыннан карала.

Шикаять контрольдә тотылучы зат тарафыннан Федераль законның 40 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнә торган шикаять карарга вәкаләтле органга, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан һәм (яисә) дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталларыннан файдаланып, электрон рәвештә (Федераль законның 40 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очрактан тыш) бирелә. Граждан тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул гади электрон имза яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш. Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Шикаять Министрлык тарафыннан Федераль законның 43 статьясында билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелә.

Шикаять Министрлык тарафыннан судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасында теркәлгән көненнән алып иң күбе 15 эш көне эчендә каралырга тиеш. Контроль объектларын тиешле риск категориясенә кертү турындагы карарга карата шикаять иң күбе биш эш көне эчендә карап тикшерелә.

Федераль законның 42 статьясындагы 1 өлешенең 3 – 8 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча шикаятьне карап тикшерүдән баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Министрлык карарларына, аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка шикаять бирү өчен нигез була алмый.»;

VII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VII. Төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген)
гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары
исемлеге

7.1. «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләүнең автоматлаштырылган системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында файдалы казылма ятмасын эшкәртүнең килештерелгән техник проекты барлыгы турында мәгълүматлар һәм файдалы казылмалар запасларын һәм җир асты суларын файдалы казылмалар запасларының дәүләт балансына куюны раслый торган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе булмауга бәйле рәвештә, соңгы алты ай эчендә гражданнар һәм оешмалар, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары мөрәҗәгатьләрендәге, массакүләм мәгълүмат чараларыннан һәм Министрлыкның структур бүлекчәләреннән булган мәгълүмат буенча ачыкланган, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия нигезендә файдалы казылмалар ятмаларын эзләүдән һәм бәяләүдән гыйбарәт җир асты байлыкларын геологик

өйрәнүне гамәлгә ашыру өчен контрольдә тотылучы затка файдалануга бирелгән җир кишәрлегендә җир һәм тау эшләрен алып бару билгеләре булу.

7.2. Узган алты ай эчендә гражданнар һәм оешмалар, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары мөрәҗәгатьләрендәге, массакүләм мәгълүмат чараларыннан һәм Министрлыкның структур бүлекчәләреннән булган мәгълүмат буенча ачыкланган, эшләр башлану сроклары җиткәннән соң 30 календарь көн узгач, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-I номерлы Россия Федерациясе Законының $23^2$ статьясында каралган тәртиптә килештерелгән һәм расланган проект документациясе нигезендә эшләр алып бару өчен кирәкле капиталь төзелеш, җиһазлар, тау эшләнмәләре, бораулау скважиналары һәм башка корылмалар җир асты байлыклары кишәрлеге чикләрендәге территориядә булмау.

7.3. Министрлык тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия гамәле срогы тәмамлану датасына кадәр 90 календарь көн кала бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле, бетерелергә тиешле башка корылмаларны бетерү эшләре булмавы билгеләнү.

7.4. Министрлык тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия гамәле срогы тәмамлану датасына кадәр 90 календарь көн кала тай эшләнмәләрен һәм каты файдалы казылмалар ятмаларындагы җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле, бетерелергә тиешле башка корылмаларны бетерү эшләре булмавы билгеләнү.

7.5. Җир асты байлыкларыннан файдаланучыдан Министрлыкка, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алган датадан 90 календарь көн узгач, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Файдалы казылмалар төрләре буенча тау эшләрен үстерү планнарын һәм схемаларын әзерләү, карау һәм килештерү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1466 номерлы карары белән расланган Файдалы казылмалар төрләре буенча тау эшләрен үстерү планнарын һәм схемаларын әзерләү, карау һәм килештерү кагыйдәләренең 13 пунктындагы өченче абзацы нигезендә графиктан тыш тау эшләрен үстерү планнарын һәм схемаларын килештерү турында гариза кермәү.

7.6. Календарь ел өчен үзгәрешләр кертелмәгән җир асты байлыкларыннан файдалануга гамәлдәге лицензия булу һәм тау эшләрен үстерү планына үзгәрешләр (өстәмәләр) кертү турында элек бирелгән гариза булмау шарты белән файдалы казылмалар чыгару күләмен тау эшләрен үстерү планында билгеләнгән күрсәткечтән 30 проценттан күбрәккә аерыла торган күрсәткечкә арттыру.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин